**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«29» 12 2020 ел № 4986

Башкарма комитетның 2019 елның 8 февралендәге 327 номерлы карары белән расланган Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын актуальләштерү максатында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2018 елның 6 августындагы 3794 номерлы район Башкарма комитеты карарына таянып,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Башкарма комитетның 2019 елның 8 февралендәге 327 номерлы карары белән расланган Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. административ регламентның 2.4, 2.5, 2.9 пунктларын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында һәм ТР рәсми хокукый мәгълүматында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү буенча урынбасары Р.С. Игътисамовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 29 12 4986 номерлы карарына 16 нчы кушымта

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты | Гаризаны теркәгәннән соң 14 көн эчендә | РФ ШтК 57.3 ст. 6 өл. |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын алу өчен:<br>1) хезмәт күрсәтү турында 2нөсхәдә гариза (1 нче кушымта);<br>2) шәхесне раслаучы документлар;<br>3) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эшли икән);<br>4) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын эшләү һәм бирү турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документлар (2 нче кушымта).<br>Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү турындагы гариза җирле үзидарә органына электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында җибәрелергә яки гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәк аша тапшырылырга мөмкин. | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бар; | РФ ШтК 57.3 ст. 4 өл. |

| | | |
|---|---|---|
| | 2) тиешле документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган очракта, ведомствоара запроска дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы ведомство карамагындагы оешманың муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмавы турында җавабы килү;<br>3) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы архитектура-төзелеш проектлаштыру, капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт алу өчен, территорияләрне планлаштыру буенча документлар булмаганда сорала (әгәр РФ ШтК нигезендә капиталь төзелеш объектын урнаштыру, территорияне планлаштыру буенча документлар булмаганда рөхсәт ителми икән) | |